**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.08.2023 Балык Бистәсе штп. № 290пи

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары төзү турында» 2013 елның 18 гыйнварындагы 08пи номерлы карарына кушымтага үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 2.1 пунктының «д» пунктчасына ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары төзү турында» 2013 елның 18 гыйнварындагы 08пи номерлы карарына кушымтага (Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 31.07.2014 №142пи, 4.08.2015. № 200пи, 2016. №101пи, 10.04.2018 № 68пи, 28.06.2019 №205пи карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), 3 пунктны яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«3. 2415 нче участок. Үзәге- "Балалар иҗаты үзәге" МБУ бинасы, Балык Бистәсе штп., Больница тыкрыгы, 6 йорт, тел.22-382. Сайлаучылар саны - 1035.

Сайлау участогы чикләренә керә:

Балык Бистәсе штп: Банк, Бертуган Бакировлар, Яшел, Н.Крупская, Яр буе, Некрасов, Больница тыкрыгы, Бакча тыкрыгы, Мәктәп тыкрыгы, Почта, Пролетар, Сосновая, Т. Корчебоков урамнары тулысынча;

Ленин урамының бер өлеше так якта 1 йорттан 77нче йортка кадәр, җөп яктан 2нче йорттан 50 нче йортка кадәр;

Җиңү урамының бер өлеше так яктан 1 нче йорттан 31 нче йортка кадәр, җөп яктан 2 нче йорттан 20Б йортка;

Совет урамының бер өлеше так яктан 1 нче йорттан 53 нче йортка кадәр, җөп яктан 2 нче йорттан 68 нче йортка кадәр".

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының

хокукый мәгълүмат рәсми порталы’’ нда һәм Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов